УДК 371.214.41=512.145

***М.М. Шәкүрова,***
***Л.М. Гыйниятуллина***

# КОММУНИКАТИВ ҺӘМ УЕН ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ НИГЕЗЕНДӘ МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫҢ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ

Данная статья посвящена особенностям обучения родному (татарскому) языку дошкольников с использованием современных технологий для подготовки к школе. В ней представлен опыт создания методических материалов для детей, изучающих татарский как родной, таких как «Авыз күрке – тел» (2021), «Әүвәл сөйлә, аннан уйна» (2022), «Балачак иле: уеннар» (2023), «Халкым җәүһәрләре» (2024) и другие. Также раскрываются содержание и методы обучения дошкольников через коммуникативные и игровые технологии. Коммуникативные технологии реализуются в процессе совместного поиска решений, проблемных ситуаций на основе активного взаимодействия участников воспитательного процесса, в том числе в игровой деятельности. Главное отличие игровой технологии от обычной игры – четко поставленная цель обучения и соответствующие методы для ее решения. В статье авторами приводятся примеры подобранных игровых технологий для реализации содержания образовательных областей с детьми старшего дошкольного возраста. Представленный в статье опыт демонстрирует, как грамотное сочетание коммуникативных и игровых технологий, подкрепленное современными методическими разработками, позволяет эффективно решать задачи обучения родному (татарскому) языку дошкольников, формируя у них прочную основу для успешного дальнейшего образования и сохраняя культурное наследие.

**Ключевые слова:** родной (татарский) язык, культура речи, коммуникативная технология, игровая технология, обучение дошкольников

This article explores the specifics of teaching Tatar to preschoolers using modern technologies to prepare them for school. It presents the experience of creating teaching materials for children learning Tatar as their first language, such as “Avyz kurke – tel” (2021), “Әүvәl soylә, annan uyna” (2022), “Balachak ile: uennar” (2023), “Khalkym җәүһәрләre” (2024), and others. It also discusses the content and methods of teaching preschoolers through communicative and game-based technologies. Communicative technologies are implemented through a collaborative search for solutions to problematic situations based on the active interaction of participants in the educational process, including through playful activities. The main difference between game-based technology and traditional play is a clearly defined learning goal and the corresponding methods for achieving it. In this article, the authors provide examples of selected gaming technologies for implementing educational content with older preschool-aged children. The article’s experience demonstrates how a well-designed combination of communication and gaming technologies, supported by modern methodological developments, effectively addresses the challenges of teaching preschoolers their native (Tatar) language, providing them with a solid foundation for successful further education and preserving their cultural heritage.

**Keywords:** native (Tatar) language, speech culture, communication technology, gaming technology, preschool education

Баланың сөйләм телен үстерү юнәлешендә төп бурычлар – сөйләм һәм тел культурасы нигезләрен формалаштыру, бала сөйләменең төрле якларын камилләштерү; аларны сәнгать, әдәбият, мәдәнияткә тарту өчен шартлар тудыру. Баланың сөйләм теленең байлыгы башка кешеләр, дуслары белән аралаша, сөйләүченең сүзен тыңлый, кабул итә белүендә, тыңлаган информациягә карата үз фикерен җиткерә алуында чагыла. Тәрбияче балаларның аралашу мөмкинлекләрен стимуллаштырырга, мәсәлән, төрле рәсемнәр, хикәяләр буенча фикер алышуда үз фикерләрен җиткерергә ярдәм итәргә тиеш. Сөйләм күнекмәләре (диалогик һәм монологик) изоляцияләнгән процесс түгел, ул аралашу барышында табигый рәвештә формалаша: яшьтәшләре, өлкәннәр белән караган мультфильм, укыган әкият, шигырь турында фикер алышканда, төрле уеннарда катнашканда, үзара аралашканда һ. б. Шулай итеп, сөйләм үсешен стимуллаштыру белем бирү барышында педагогик эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә көн саен тормышка ашырылырга тиеш. Тәрбиячеләр яттан шигырьләр өйрәтү, тизәйткечләр әйтү, җырлар җырлау, уеннар оештыру аша балаларның сөйләм телләрен баеталар, камилләштерәләр [1: 3].

Сөйләм культурасы ул – иң беренче чиратта, сөйләм нормаларын үзләштерү: авазларны дөрес итеп әйтеп, лексик һәм грамматик чаралардан дөрес файдалану. Бакчада тәрбиячеләр ана теле дәресләрендә генә түгел, көн дәвамында төп игътибарны, программа таләп иткәнчә, баланың авазларны дөрес әйтү әдәбен һәм бәйләнешле сөйләмен системалы үстерә, сүз байлыгын даими баета баруга һәм җөмләләрне грамматик яктан дөрес сөйли белүләренә юнәлтә. «Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты» таләпләре нигезендә балаларны әдәбият, музыка сәнгате, халык иҗаты белән таныштыруны, аларда сәнгати-эстетик һәм музыкаль зәвык формалаштыруны максат итеп куя [6].

Мәктәпкә әзерлек һәм зурлар төркемнәре өчен «Мин», «Тирәяк, көнкүреш», «Туган ил», «Татар дөньясы» кебек лексик темалар белән бәйләп, методик әсбаплар эшләнде. Алар өч өлештән тора: 1) 4–5 яшьлек балалар өчен махсус сайлап алынган шигырьләр, әлеге текстлар белән эшләгәндә аларга үз фикерләрен җиткерергә ярдәм итә торган эш алымнарын куллану (шигырьнең тексты белән танышу һәм аны ишетеп аңлау, сүзлек белән эш, текстка карата тәкъдим ителгән биремнәр белән эшләү (текст буенча әңгәмә үткәрү, сорауларга җавап бирү, рәсемнәр белән эшләү һ. б.); 2) шигъри һәм музыкаль тоем, ритм хисен, музыкаль хәтерне үстерү һәм музыкаль зәвык формалаштыру өчен татарча җыр тексты белән танышу, сүзлек эше башкару, текстка карата тәкъдим ителгән биремнәр эшләү, җырның музыкасы белән танышу, җырларга өйрәнү; 3) ишетү һәм күрү хәтерен яхшырту максатыннан халык иҗатыннан алынган эндәшләр белән таныштыру, табигатькә, кош-кортларга эндәшләр белән бәйле төрле иҗади биремнәр эшләү, рәсемнәрне буяп яки ясап бетерү һ. б.

Тематик блокларга килгәндә, беренче тема «Мин» баланың үз мөнәсәбәтен белдерүгә юнәлтелгән лексик берәмлекләр белән эш итүне күздә тота: гаилә, өлкәннәргә, әти-әниләргә, әби-бабайларга мөнәсәбәт, балалар бакчасы, дуслар, тәрбиячеләр белән исәнләшә белү, аларны сәламләү, балалар өчен язылган әсәрләрнең геройлары белән эшләү, үзләренең шөгыльләре, җәйге яллары турында җөмләләр төзеп әйтә белү, кечкенә диалоглар төзү һ. б. Шул рәвешле, 4–5 яшьлек балалар өчен эшләнгән «Телнең күрке – сүз» дигән методик әсбапта, Шәйхи Маннурның «Яратам», Шәүкәт Галиевнең «Җирдә миңа ни кирәк» шигырьләренә нигезләп, төрле күнегүләр, биремнәр тәкъдим ителә:

1. Рәсемнәргә карап, «Мин кемне яратам? Мин нәрсә яратам?» сорауларына бергәләп җавап бирү.

2. Җөмләләрне тулыландырып, җөмләләр төзергә өйрәтү: Мин яратам. – Мин әтине яратам. – Мин апаны яратам. – Мин өйне яратам.

3. Үзең яшәгән өйнең кирәклеген, туганнарның кадерле булуын төшендерү максатыннан, «Яратам мин өемне» дигән темага балалар белән әңгәмә үткәрү һ. б. [1: 4–5].

«Тирә-як, көнкүреш» дип аталган икенче тема балаларны иҗади, актив, мөстәкыйль, әйләнә-тирәне күзәтә, табигатьне саклый белә торган итеп тәрбияләүгә юнәлтелә. Яраткан уеннар, уенчыклар, халык әкиятләре, хайваннар, үсемлекләр дөньясы кебек темалар тәкъдим ителә. Алар сөйләмне үстерүне, тел байлыгын арттыруны күз уңында тота.

«Туган ил» темасы көндәлек тормыш, татар халкы һәм Россия Федерациясе субъектлары халыкларының гореф-гадәтләре, традицияләре аша укучыларда гражданлык, патриотик хисләр, туган илгә карата хөрмәт, мәхәббәт уяту, аны саклау, Россия һәм Татарстанның дәүләт символлары (гимн, флаг, герб), шәһәрләре, авыл тормышы һ. б. турында мәгълүмат бирүгә юнәлтелгән.

«Татар дөньясы» темасын өйрәнгәндә татар халкының рухи тормышы, мәдәнияте: гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре (Сабантуй, Нәүрүз), уеннары («Башмакчы», «Ак калач», «Без, без, без идек», «Йөзек салыш»), милли өс киемнәре, татар халык ашларына багышланган текстлар белән эшләү күздә тотыла.

Бүгенге көндә укытучылардан заман таләпләренә туры килә торган белем бирү, баланы шәхес буларак тәрбияләү, җәмгыятьтә үз урынын табарга әзерләү сорала. Бу таләпләрне тормышка ашыруда укытучыга яңа технологияләр ярдәм итә. Технология – (грек теленнән алынган сүз; сәнгать, осталык дигән мәгънәне белдерә) фәннең яисә җитештерү өлкәсенең билгеле бер тармагында кулланылган ысуллар һәм алымнар җыелмасы ул. Педагогик технология укытуны, белемнәр үзләштерүне, идея-фикерне, төрле чараларны, ысулларны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Алар арасында модульле укыту методы (Т.И. Шамова, П.И. Третьяков, И.В. Сенновский), үстерелешле укыту методы (И.С. Якиманская, Л.В. Занков һ. б.)

уен технологиясе (Ш.А. Амонашвили, О.В. Канарская, Д.Б. Эльконин), проблемалы-эвристик укыту методы (А.В. Хуторской), проектлар укыту методы (Дж. Дьюи), мәгълүмат чаралары ярдәмендә укыту методы (Е.С. Полат), алгоритмнар нигезендә мәгълүмат чаралары кулланып укыту методы (Н.Н. Алгазина), проблемалы укыту ысулы (М.И. Мәхмүтов), коммуникатив технология (Е.И. Пассов) һ. б.

Коммуникатив технология мәктәпкәчә яшьтәге балалар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләргә карый. Липецк шәһәрендәге чит ил мәдәниятен коммуникатив методика нигезендә укыту үзәге галиме Е.И. Пассов аралашуга өйрәтү технологиясенә корылган күнегүләрнең ике төрен билгели: шартлы тел һәм тел күнегүләре [4]. Шартлы тел күнегүләре, күнекмәләр үстерү максатыннан, махсус оештырыла. Бу күнегүләр бер типтагы лексик берәмлекләрнең кабатлануына нигезләнә:

– *Бу малаймы? Аның исеме Камилме? Аның исеме ничек?*

– *Бу кызмы? Аның исеме Алсумы? Аның исеме ничек?*

– *Бу Актырнакмы? Этнең кушаматы ничек? Ул кечкенәме?*

– *Бу кем? Аның алтын тарагы бармы? Малай таракны урлаганмы? Малай дөрес эшләгәнме?* һ. б.

Тел күнегүләре аша лексика һәм грамматиканы киңрәк өйрәнү мөмкинлеге тормышка ашырыла. Мәсәлән, *белән* бәйлегенең диалогик һәм монологик сөйләмне камилләштерү активлыгына карап, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга түбәндәге грамматик күнегүләрне тәкъдим итәргә була:

1. Кем белән?

– *Кем белән барасың?*

– *Әти белән барам.*

– *Әти белән барасыңмы?*

– *Әти белән барам.*

2. Русча әйтегез: Кем белән? – С кем?

Кем белән? *Әти белән – с папой, әни белән – с мамой, әби белән – с бабушкой, бабай белән – с дедушкой* һ. б.

3. Русча әйтегез: Нәрсә белән? – С чем?

Нәрсә белән? *Песи белән – с кошкой, эт белән – с собакой, май белән – с маслом, шикәр белән – с сахаром* һ. б.

Балаларның иҗади мөстәкыйльлеген үстерүдә, туган телгә карата ихтирам тәрбияләүдә, аларны кечкенәдән халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштырып барып, сөйләшергә, аралашырга өйрәтүдә тел күнегүләре бик мөһим роль башкара. Халык авыз иҗаты әсәрләре балаларны тәрбияләү, үзара аралашырга, әйләнә-тирә дөньяны танып белергә, төрле мөнәсәбәтләр корырга өйрәтү өчен бай материал хезмәтен үти. Татар әкиятләрендә, нигездә, яхшылык явызлыкны җиңә, геройларның төп сыйфатлары булып батырлык, кыюлык, өлкәннәргә, дусларыңа карата хөрмәт, намуслылык, тугрылык, миһербанлылык санала. Әкиятләрне укый башлаганчы, тәрбияче аларның авторлары

булырга мөмкинлеген һәм татар халкының телдән телгә күчеп килеп сакланган әкиятләре дә барлыгын әйтеп китә, сүзлек эшен башкара. Татар язучылары, шагыйрьләре язган әкиятләрне укыганда, авторлар белән дә кыскача гына таныштырып китү сорала. Шул рәвешле, сабыйлар татар әдәбияты дөньясына тәүге адымнарын атлый. Әкиятнең балалар тарафыннан ничек кабул ителүе аның укылу рәвешенә дә бәйле. Шуңа күрә тәрбиячененң әкиятне дөрес интонация белән, төрле хәрәкәтләр, мимикаларны дөрес кулланып укуы зарур. Сөйләмнең сәнгатьлелеге, эмоциональ байлыгы әкиятнең эчтәлеген аңларга да ярдәм итә. Бала әкияттәге вакыйгаларның чынлыгына ышана, һәр герое белән бергә шатлана яки борчыла. Бу, үз чиратында, сабыйның аң һәм белем эшчәнлеген активлаштырырга ярдәм итә. Тәрбиячедән әкиятләрне берничә кат уку сорала. Беренче тапкыр укыганда бала кичерешләрне дөрес аңламаска да мөмкин. Ул вакытта ул бары әкиятнең сюжетын гына истә калдыра, тәрбияви нечкәлекләренә игътибар итми. Әкиятләрнең күбесе буенча мультфильмнар эшләнгән. Әкият тексты белән бер кат танышканнан соң, әлеге мультфильмны карау балаларга сюжетны, геройларны истә калдырырга ярдәм итә. Әсбапта һәр әкияттән соң аның тексты белән эшләү, балаларның игътибарлылыгын арттыру, сөйләм телен үстерү өчен төрле грамматик биремнәр, һәр әкият ахырында буяу өчен рәсем тәкъдим ителә. Сорауларга җавап бирү, җөмләләр төзү, рәсемнәр белән эшләү аша кече яшьтәге балаларның логик фикерләү сәләте формалаштырыла, сөйләме баетыла, рәсемнәр буяу кул, бармак моторикасын үстерә [8: 4].

Туган телгә карата мәхәббәт һәм ихтирам, милләтара дуслык хисен кече яшьтән үк тәрбияләү мөһим. Бу юнәлештә төрле милләт вәкилләренең, бигрәк тә Татарстан Республикасында бердәм һәм тату булып яшәүче татар, рус, башкорт, чуваш, мари, мордва һәм удмурт халыкларының әкиятләрен уку, әңгәмә үткәрү, ул халыкларның яшәү рәвеше, милли ашлары, киемнәре, бәйрәмнәре белән таныштыру, уеннарын уйнау зур ярдәм була ала [5: 15].

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында уен технологиясен куллану да игътибарга лаек. Уен – танып белүгә кызыксыну уята һәм балаларның акыл эшчәнлеген арттыра, аларны активлаштыра торган чара ул. Уен ярдәмендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларда зирәклек, өлгерлек, коллективта үзеңне тота белү, кыюлык кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә. Дидактик уеннар 4–5 яшьлек балаларда фикерләү тизлеген, күзаллау сәләтен үстерергә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләргә, предметлар арасында охшашлык һәм аермаларны табарга, туган телдә аралашырга өйрәтә. Уен барышында баланың кичерешләренә кызыксыну уяту, хисләрен аңлату, үзенең эмоциональ халәтен белдерә алу мөмкинлеге туа («Кино төшерү», «Һава торышы», «Елаклар утравы», «Хисләр белән уртаклашу» һ. б.). Уеннарны дидактик уеннар һәм лексик-грамматик уеннарга бүлеп йөртәләр. Дидактик уеннар үзләре өч төргә бүленә:

1. Тренинг характерындагы дидактик уеннар («Кино төшерү», «Доктор Айболит», «Юл күрсәтүчеләр», «Салават күпере», «Уртак бүләк» һ. б.).

2. Сөйләм этикеты кагыйдәләре белән бәйле дидактик уеннар («Тылсымлы сүзләр табыйк», «Кунакларны сәламләү», «Телефоннан сөйләшү», «Исәнләшү», «Саубуллашу» һ. б.).

3. Эмоцияләр белән бәйле дидактик уеннар («Мода театры», «Эмоцияләр», «Кечкенә Янут», «Кәеф лотосы» һ. б.).

Лексик-грамматик уеннар («Әйләнә-тирәбездә нәрсә бар?», «Капчыкта нәрсә?», «Бу кем?», «Хатаны төзәт», «Парыңны тап» һ. б.) [4: 38].

Тренинг характерындагы дидактик уеннарның берсенә – «Уртак бүләк» уенына тукталып үтик. Уенның максаты – конфликтлы ситуациядән чыгу юлын сайлау, яшьтәшләре белән хезмәттәшлек итү күнекмәләрен үстерү. Җиһазлау итеп җиде таҗлы чәчәк алына. Уенның барышында балаларга түбәндәге ситуация тәкъдим ителә:

*Төркемгә бүләк итеп чәчәк бирәләр. Аның таҗы җиде генә, ә төркемдә балалар саны күбрәк. Һәр бала, уртак чәчәктән бер таҗны өзеп алып, бер генә теләк әйтә ала. Ләкин балаларның барысына да таҗлар җитми. Бу ситуациядән чыгу юлын ничек табарга?*

Беренче вариант. Өстәлдә кәгазьдән эшләнгән зур чәчәк ята, аның җиде таҗы магнит белән беркетелгән. Балалар, берәм-берәм чыгалар да, бер таҗны алып, теләкләрен әйтәләр һәм аны кабат чәчәккә беркетеп куялар.

Икенче вариант. Уенда катнашучы балалар туган конфликтлы ситуацияне үзләренчә хәл итәләр. Соңыннан балалар белән әңгәмә үткәрелә: һәркем үз теләген белдерә алдымы, барлык балалар да теләкләрен әйтә алдылармы, нәрсә эшләргә мөмкин булыр иде һ. б.

Өченче вариант. Тәрбияче балаларга таҗлар саны буенча 7 төркемгә бүленергә һәм бергәләп бер теләк әйтергә тәкъдим итә. Балалар үз теләкләре буенча төркемнәргә берләшәләр. Тәрбияче төркемнәр сайлаган теләкләрнең кабатланмавын тәэмин итә.

Мондый уеннар балага үзенең халәтен аңларга, башкаларга карата игътибарлы булырга, ана телендә комплиментлар ясарга, төрле бәхәсләрдән чыгу юлын табарга булыша. Уйный-уйный, бала үз фикерен, мөнәсәбәтен туган телендә белдерергә өйрәнә, хәтерен яхшырта, тагын да кыюлана, активлаша бара, башкалар янында үзен иркен, табигый тота.

Тренинг характерындагы дидактик уеннар балага тормышка әзерлек нигезләрен җиткерә торган заманча технологик чараларның берсе булып тора. Алар җәмгыятьтә кабул ителгән социаль тәртип модельләрен өйрәтүгә корыла. Бу төр уеннарның эчтәлеге кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм үз-үзләрен тоту стильләрен чагылдырган тормыштан алынган ситуацияләргә нигезләнә: туган телдә исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтә белү, гафу үтенү һ. б.

Дидактик уен-тренинг баланың уңай образын формалаштыруга ярдәм итә, үзен чит күз белән күрергә, социаль толерантлыкка өйрәтә. Ул балаларда игелеклелек сыйфаты тәрбияли, аралашу осталыгын үстерә, бер-берсенә карата симпатия тудыра. Әлеге уеннар балага хисләр телен, үз халәтен, кәеф төсмерләрен, кичерешләрен аңлау сәләте булдырырга булыша. Алар эмоциональ халәтне сүз, мимика, пантомимика аша аңларга гына түгел, ә белдерергә дә өйрәтә. Мәсәлән, төрле хисләрне тану һәм белдерү сәләтен үстерү максатыннан, «Кечкенә Янут» уены уйнатыла. Бер бала – Кечкенә Янут, калган балалар – аның шәүләләре була. Балалар келәмгә утыралар яки бер рәткә басалар. Янут «елга»га якынлаша һәм төрле хисләрне (курку, гаҗәпләнү, шатлык) сурәтли, ә балалар аларны мимика һәм ишарәләр ярдәмендә төгәл чагылдыралар. Аннары Янут роленә, чиратлап, башка балалар да сайлана. Уен күмәк җыр белән тәмамлана [3: 18].

Сөйләм этикеты кагыйдәләре белән бәйле дидактик уеннар белән бергә лексик, грамматик уеннарга да зур урын бирелә. Укыту барышында уен элементларын кертеп җибәрү балаларның игътибарлылыгын яхшыртырга, хәтерләрен үстерергә, сүз байлыкларын арттырырга булышлык итә. Мондый төр уеннар мәгънәдәш яки капма-каршы мәгънәле булган сүзләрне сайлап алу осталыгы булдыруга, кем яки нәрсә, нинди сорауларына җавап бирергә, бәйләнешле сөйләм үстерүгә этәргеч ясыйлар («Киресен әйт», «Башкача әйт», «Төрле сүзләр», «Кирәкле аваз», «Кем күбрәк belә?» һ. б.).

Сөйләм этикеты кагыйдәләре белән бәйле дидактик уеннардан «Кунакларны сәламләү» дигән уенга тукталып китик. Бу уенның максаты – балаларга безнең илдә һәм чит илләрдә кунаклар каршылау нормаларын өйрәтү, кунакчыллык тәрбияләү. Балалар янына кунакка зәңгәр вертолётта танылган әкият геройлары – Чебурашка һәм Крокодил Гена, Су анасы, Шүрәле һәм доктор Айболит килә. Кунакларны төрлечә сәламләргә һәм кабул итәргә була. Мәсәлән, Чебурашканың әле кечкенә булуын, ә доктор Айболитның өлкән яшьтә икәнлеген, Су анасының суда, Шүрәленең урманда яшәвен исәпкә алырга кирәк. Сәламләгәндә мимика, ишарәләр кулланырга, түбәндәге кагыйдәләрне үтәргә тәкъдим ителә: кунакның күзләренә карарга, елмаеп, башны бераз иеп сөйләшергә, ашыкмаска һ. б. Уен барышында «сәлам» сүзен кайчан һәм кемгә әйтү урынлы булуы ачыклана (дустыңа әйтеп буламы яки бу сүзне олы кешегә әйтергә ярыймы һ. б.) [3: 13–14].

Кунак чакыру һәм аның белән бәйле сөйләм репликалары, Идел буенда яшәүче башка халыкларның милли ашлары, өс-киемнәре, музыка уен кораллары, җырлары белән бәйләп, халыклар арасында дуслык, туганлык хисләрен саклау, бер-береңне хөрмәт итүгә ирешүне балага кечкенәдән сеңдерергә кирәк.

Йомгаклап әйткәндә, дидактик уеннар ярдәмендә баланың үз-үзенә ышанычы арта, сөйләм этикеты кагыйдәләрен саклап, ул иптәшләре белән аралаша башлый. Тәкъдим ителгән уеннарны төрле җирдә һәм төрле катнашучылар белән уйнарга була. Уенның

дәвамлылыгы балаларның аңа кызыксынуына бәйле. Иң мөһиме – ирек, шатлык, иҗат һәм бердәмлек атмосферасы булдыру, бала белән аның үз телендә аралашу. Шулай итеп, дидактик уеннар балаларның акыл эшчәнлеген активлаштырырга мөмкинлек тудыра, барлыкка килгән кыенлыклар аларны уйланырга, куелган проблемалы ситуациядән чыгу юлын эзләргә мәҗбүр итә, стандарт булмаган чишелешләр табарга, креатив фикерләргә этәргеч ясый.

**Әдәбият**

1. Авыз күрке – тел. Методик әсбап: Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен (6–7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү өчен) / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. Казан, 2021. 40 б.

2. Әүвәл сөйлә, аннан уйна. Методик әсбапка кушымта: Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен: (5–7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү өчен) / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. Казан, 2022. 44 б.

3. Балачак иле: уеннар. Методик әсбап: Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. Казан, 2023. 40 б.

4. Балачак иле: шигырьләр, җырлар, эндәшләр. Методик әсбап: Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. Казан, 2023. 60 б.

5. Идел Буе халыклары әкиятләре. Методик әсбап: Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. Казан, 2024. 40 б.

6. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы / Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева ред.; русчадан Р.И. Хәлиуллина тәрҗ. Казан: Хәтер, 2016. 357 б.

7. *Пассов Е.И.* Коммуникативный метод обучения иноязычному говорению. М.: Просвещение, 1985. 207 с.

8. Халкым җәүһәрләре. Методик әсбап: Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. Казан, 2024. 60 б.

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсум кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гыйниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Шакурова Муслима Магесумовна,***
*кандидат филологических наук, доцент, ведущий научный сотрудник отдела национального образования Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*vitorioarpad@gmail.com*

***Гиниятуллина Лилия Миннулловна,***
*доктор филологических наук, доцент, ведущий научный сотрудник отдела национального образования Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*gin_liluk@mail.ru*